ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 16 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә:

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы Президентына,» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле

органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы Президентына,» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешнең өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентыннан яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары компетенциясе**

1. «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Президенты:

әлеге Законның 1 статьясы нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларны, шул исәптән әлеге Законның 1 статьясы нигезендә тапшырылган вәкаләтләр өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын, чыгарырга һәм аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга хокуклы;

граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыруны һәм аны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

әлеге Законның 1 статьясы нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турындагы хисаплылыкның эчтәлегенә һәм рәвешләренә, шулай ук мондый хисаплылыкны тапшыру тәртибенә карата таләпләр билгели;

үз компетенциясе чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Законның 1 статьясы нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

әлеге Законның 1 статьясы нигезендә тапшырылган вәкаләтләр үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән очракта, җирле үзидарә органнары тарафыннан аларны гамәлгә ашыруны туктату турында закон чыгару инициативасы белән чыга;

федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 8 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 7 статьясындагы алтынчы абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш) «төгәл һәм сыйфатлы гамәлгә ашырылуына контрольлек һәм күзәтчелек итү» сүзләрен «гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын тикшереп тору» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $13^6$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$13^6$) муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма эш йөртү органнарының (җирле администрацияләрнең) мәгариф өлкәсендә муниципаль идарәне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларын (җирле администрацияләр башлыклары урынбасарларын, җирле администрацияләрнең структур бүлекчәләре яисә җирле администрацияләрнең тармак органнары җитәкчеләрен) билгеләп куюны килештерүне гамәлгә ашыра;».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 21 июль
№ 44-ТРЗ